Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

30 май, 2023 ел № 10

«Көек авылында җир кишәрлекләреннән файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә - торак төзелешенә хезмәт күрсәтү» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы карары проекты буенча Көек авылында иҗтимагый фикер алышуларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлегендә (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108 номерлы, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. «Көек авылында җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - торак төзелешенә хезмәт күрсәтү » Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башлыгы карары проекты буенча Көек авылында иҗтимагый фикер алышуларын (алга таба - Проект) билгеләргә (кушымта).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 6 июнендә, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Питрәч ав., Совет ур., 18 нче йорт адрес буенча;

2.3. адресы буенча, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: 422774, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Богородский ав., Үзәк

ур., 57Б/1 й. адресы буенча (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

2.4. Богородский авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында 2023 елның 28 апрелендә түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский ур., Үзәк ур., 57Б/1 йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында проектның демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештырырга.

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм «Вперед» («Алга») район газетасында урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «БОГОРОДСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» * ИНН 1633000835
СОВЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Богородский авыл җирлеге башлыгы карарына кушымта
30.05.2023 ел № 10

Проект

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

___ _____ 2023 ел № __

Көек авылында җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - торак төзелешенә хезмәт күрсәтүгә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенең 2023 елның ____ _________ иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән тәкъдимнәрен исәпкә алып карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләрен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирергә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:140301:3104, мәйданы 1740 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) «Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү»,

- ж/к кадастр номеры 16:33:140301:2290, мәйданы 1000 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, Көньяк ур., 98а й. - шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1) «Торак төзелешенә хезмәт күрсәтү»,

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов